РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

СОВЕТ САТЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

422070, Республика Татарстан, Сабинский район, С.Сатышево, ул. Ленина, 17Б
тел. (8262) 2-24-16

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

САТЫШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422070, Татарстан Республикасы, Саба районы, Сатышавылы, Ленин урамы, 17Б йорт
тел. (8262) 2-24-16

e-mail: Sat.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
21.06.2024

КАРАР
№12

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган җирле салым суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 һәм (яки) 70 статьяларында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада физик затларның бурычы булуы.

2. Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 маендагы 12 номерлы «Җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керүен билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/satish адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә калдырам.

Сатыш авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Шафигуллин